КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1400

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затларның, аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 19 март, 171 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затларның, аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 19 март, 171 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында» сүзләренә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында» сүзләренә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «рәсми сайтларда» сүзләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «рәсми сайтларда» сүзләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затларның, аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

исемендә татар текстында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларында» сүзләренә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «(алга таба - рәсми сайтлар)» сүзләрен «(алга таба тиешенчә - рәсми сайтлар, башкарма органнар)» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы белешмәләр, цифрлы финанс активлары, хисап чорына кадәрге цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин